ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.01.2023 п.г.т. Алексеевское № 12

**Алексеевск муниципаль районында
«Татарстан Республикасында елның
иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе»
конкурсын үткәрү буенча муниципаль
конкурс комиссиясен төзү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 2015 елның 1 июнендәге 391 номерлы карары һәм «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе президиумының 28.12.2022 № ПР-73-1 карары белән расланган, «Татарстан Республикасыда елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы нигезләмәсе нигезендә,

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районында «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсын үткәрү буенча муниципаль конкурс комиссиясен оештырырга һәм аның эш регламентын расларга (1,2 нче кушымта).

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// /alekseevskiy.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А. Гайнуллин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башкарма комитетының
16.01.2023 ел, № 12 карарына
1 нче кушымта

**Составы**
**Алексеевск муниципаль районында «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсын үткәрү буенча муниципаль конкурс комиссиясе**

**Комиссия рәисе:**
Гайнуллин О.А. – Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе

**Комиссия рәисе урынбасары:**
Свистунов И.К. – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килештерү буенча)

**Комиссия секретаре:**
Увакина В.В. – Алексеевск шәһәр җирлеге Советы Рәисе урынбасары (килештерү буенча)

**Комиссия әгъзалары:**
Тимонина Н.Ю. – «Алексеевск районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге»ДКУ җитәкчесе (килештерү буенча)
Йосыпова Г.Ә. – Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башкарма комитетының
16.01.2023 ел, № 12 карарына
2 нче кушымта

**Регламенты**
**Алексеевск муниципаль районында «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсын үткәрү буенча муниципаль конкурс комиссиясе эше**

1. Алексеевск муниципаль районында «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсының (алга таба - Комиссия) муниципаль конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда аның исемлек составындагы кимендә өчтән ике әгъза катнашса, тулы хокуклы була.

2.Комиссия карарлары ачык тавыш бирү аша кабул ителә һәм алар өчен комиссия әгъзаларының 50 проценттан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигезлеге очрагында Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

3.Комиссия карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә һәм комиссия рәисе һәм әгъзалары тарафыннан Комиссия утырышы узган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә имзалана.

4.Комиссия эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә заявкаларны кабул итү срогы башланган көннән алып конкурсның I этабында катнашуга гаризалар кабул итә һәм теркәп бара.

5. Гаризалар кабул итү тәмамланган көннән алып эш көннәрендә исәпләнеп комиссия конкурсның I этабында катнашуга тәкъдим ителгән гаризаларны «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» конкурсына нигезләмәнең 4 нче кушымтасы нигезендә критерийларга туры китереп бәяли, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 1 июнендәге 391 номерлы «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» карары белән расланган конкурсның II этабында катнашырга дәгъва кылучы катнашучыларны билгеләнгән тәртиптә билгели.

6.Конкурсның I этабын уздыру нәтиҗәләре буенча Комиссия конкурсның II этабына тәкъдим итә:

1) «Татарстан Республикасында елының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсының II этабында нигезләмәгә 2.1 кушымтасы нигезендә форма буенча катнашу турында гариза;

2) комиссия төзегән һәм аның составы расланган муниципаль хокукый актның күчермәсе;

3) конкурсның I этабында катнашучылар исемлеге;

4) муниципаль конкурс комиссиясе рәисе имзалаган муниципаль конкурс комиссиясе утырышының йомгаклау беркетмәсе;

5) Нигезләмәнең 3.9 пункты нигезендә конкурсның II этабында катнашырга дәгъва кылучы катнашучыларның гаризалары.

7.Комиссия карарларына карата катнашучылар һәм дәгъва кылучылар тарафыннан билгеләнгән закон тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**